ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

22 сентябрь, 2025 ел № 1/11

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге
Башкарма комитеты Җитәкчесе вазыйфасын
биләүгә конкурс турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 22 статьясы, «Татарстан Республикасының муниципаль хезмәт турында кодексы» 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 19 статьясы, шәһәр Уставының 28, 40 статьялары нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурсны 23.10.2025 14:00 сәгатьтә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетында Хәсән Туфан проспекты, 23 йорт, 402 кабинетта үткәрергә дип игълан итәргә һәм аны 1 нче кушымта нигезендә үткәрергә.

2. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс комиссиясе составына түбәндәге затларны билгеләргә:

1) Агапов Виталий Васильевич – Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советы депутаты;

2) Мөхәмәдиев Марат Фәнис улы – Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советы депутаты;

3) Хәлиуллина Жанна Евгеньевна – Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советы депутаты.

3. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Җитәкчесе белән контракт проектын 2 нче кушымта нигезендә расларга.

4. Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс турында» 2022 елның 25 февралендәге 13/9 номерлы Карарын көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге Карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырырга, шулай ук Яр Чаллы шәһәренең «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

6. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының регламент, хокук тәртибе һәм халыкның иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

Шәһәр Советының
1/11 Карарына
1 нче кушымта
22 сентябрь, 2025 ел

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе

1.Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Җитәкчесе (алга таба – Башкарма комитет Җитәкчесе) вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү тәртибе һәм шартлары «Россия Федерациясе муниципаль хезмәте турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасының муниципаль хезмәт турында кодексы» 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, шәһәр Уставы нигезендә билгеләнә.

2. Конкурсның төп максаты – муниципаль берәмлекнең башкарма–күрсәтмә бирү органы белән нәтиҗәле идарә итүне тәэмин итү өчен Башкарма комитет Җитәкчесе вазыйфасына кандидатларны (алга таба – кандидат) билгеләү.

3. Кандидатларны карау өчен Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советы (алга таба – Шәһәр Советы) тарафыннан конкурс комиссиясе оештырыла.

4. Конкурс комиссиясен формалаштырганда аның әгъзаларының яртысы – Шәһәр Советы тарафыннан, икенче яртысы – Татарстан Республикасы Рәисе Указы белән билгеләнә. Комиссиянең эш тәртибе әлеге нигезләмә нигезендә билгеләнә.

5. Конкурс комиссиясе алты кешедән тора.

6. Конкурс Шәһәр Советы карары белән игълан ителә. Конкурс конкурс шартлары, аны үткәрү датасы, вакыты һәм урыны, контракт проекты басылып чыккан көннән алып кимендә 20 көннән соң үткәрелә.

7. Конкурс кандидат тарафыннан түбәндәге шартлар үтәлгән очракта үткәрелә:

1) Россия Федерациясе гражданлыгына яисә Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы, шул нигездә җирле үзидарә органнарына сайланырга хокуклы чит ил гражданлыгына ия булу;

2) югары белемле булу;

3) ике елдан да ким булмаган муниципаль хезмәт стажы яисә дүрт елдан да ким булмаган белгечлек, юнәлеш буенча хезмәт стажы булу (муниципаль хезмәт стажын билгеләгәндә шулай ук дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларында һәм аларга тиңләштерелгән хәрби хезмәт вазыйфаларында һәм федераль дәүләт хезмәтенең башка төр вазыйфаларында хезмәт стажы исәпкә алына);

4) кимендә биш ел идарә итү эшчәнлеге тәҗрибәсе булу (идарә итү эшчәнлеге дигәндә дәүләт органы, муниципаль орган, оешма җитәкчесе, җитәкче урынбасары, шулай ук аларның структура бүлекчәләре җитәкчеләре вазыйфаларында эшләү күздә тотыла).

8. Конкурста катнашырга теләүче затлар Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының персонал белән эшләү һәм муниципаль хезмәт идарәсенә (алга таба – персонал белән эшләү һәм муниципаль хезмәт идарәсе) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибенең (алга таба –тәртип) 1 нче кушымтасы нигезендә гариза тапшыра.

Күрсәтелгән гаризага түбәндәге документлар теркәлергә тиеш:

1) «Россия Федерациясе дәүләт хезмәтенә һәм Россия Федерациясендә муниципаль хезмәткә кергәндә белешмәләр бирүнең һәм аларны актуальләштерүнең кайбер мәсьәләләре турында» 2024 елның 10 октябрендәге 870 номерлы РФ Президенты Указы белән билгеләнгән формада үз кулы белән тутырылган һәм имзаланган анкета һәм 3х4 см төсле фоторәсем;

2) паспортның яисә аны алыштыручы документның төп нөсхәсе һәм күчермәсе (документның төп нөсхәсе документлар тапшырганда һәм конкурска килгәч шәхсән күрсәтелә);

3) югары белемне, хезмәт стажын һәм квалификацияне раслый торган документлар:

– хезмәт кенәгәсенең һәм (яисә) хезмәт эшчәнлеге турында законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән белешмәләрнең төп нөсхәсе һәм күчермәсе;

– һөнәри белем турында, шулай ук, гражданның теләге буенча, өстәмә һөнәри белем турында, гыйльми дәрәҗә, исем бирү турында документның төп нөсхәсе һәм күчермәсе. Конкурсант өстәмә рәвештә үзенең һөнәри әзерлеген характерлаучы башка документларны да тапшырырга мөмкин;

4) үзенә, хатынына (иренә) һәм балигъ булмаган балаларына 2024 ел өчен керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмә.

Белешмә кәгазьдә бирелә, Россия Федерациясе Президентының рәсми сайтында урнаштырылган «БК белешмәсе» махсус программасын кулланып тутырыла, аңа сылтама шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә дәүләт хезмәте өлкәсендә федераль дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында урнаштырыла. Белешмә басмасында хезмәт мәгълүматы булган зоналар (штрихлы кодлар һ.б.) төзелә, аларда нинди дә булса тамга ясау рөхсәт ителми;

5) Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының 2025 елның 14 апрелендәге 201н номерлы боерыгы белән расланган форма буенча муниципаль хезмәткә керүгә комачаулаучы авыру булмау турында медицина учреждениесе бәяләмәсе;

6) индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслый торган документның төп нөсхәсе һәм күчермәсе;

7) Россия Федерациясе территориясендә яшәү урыны буенча салым органында физик затны исәпкә кую турында таныклыкның төп нөсхәсе һәм күчермәсе;

8) хәрби исәпкә алу документларының төп нөсхәсе һәм күчермәсе - запаста торучы гражданнар һәм хәрби хезмәткә алынырга тиешле затлар өчен;

9) хөкем ителү булу (булмавы) турында белешмә;

10) муниципаль хезмәткә кергән ел алдыннан өч календарь ел эчендә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге һәркем өчен ачык булган мәгълүмат урнаштырылган сайтлар һәм (яки) сайтларның адреслары турында мәгълүмат, шулай ук аларны идентификацияләргә мөмкинлек бирә торган мәгълүматлар;

11) әлеге тәртипнең 2 нче кушымтасы нигезендә шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык.

9. Комиссия конкурска тапшырылган документларны өстәмә тикшерү, шулай ук конкурсантлар турында башка мәгълүматны сорату хокукына ия.

10. Гариза биргән затка документларның исемлеген һәм аларны алу датасын күрсәтеп, документларны алу хакында язу (расписка) бирелә.

Башкарма комитет Җитәкчесе вазыйфасына кандидат теләсә кайсы вакытта гаризасын кире алырга хокуклы.

11. Тапшырыла торган документларны кабул итеп алу һәм тикшерү персонал белән эшләү һәм муниципаль хезмәт идарәсе тарафыннан башкарыла. Документларның төп нөсхәләре мөрәҗәгать итүчегә аларны тапшырган көнне кайтарыла, күрсәтелгән документларның күчермәләре эшкә (дело) формалаша.

12. Әлеге тәртипнең 8 пунктында күрсәтелгән документлар Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты бинасында эш көннәрендә персонал белән эшләү һәм муниципаль хезмәт идарәсендә 03.10.2025 башлап 22.10.2025 кадәр (аны да кертеп) 09.00 сәгатьтән 15.00 сәгатькә кадәр (төшке аш вакыты 12.00 дән 13.00 сәгатькә кадәр) түбәндәге адрес буенча тапшырыла: Яр Чаллы шәһәре., Хәсән Туфан пр., 23 йорт, 394 каб.

Документларны вакытында тапшырмау, аларны тулы күләмдә тапшырмау яисә рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшыру аларны кабул итүдән баш тарту өчен нигез булып тора.

13. Әлеге тәртипнең 12 пунктында билгеләнгән вакыт узгач, персонал белән эшләү һәм муниципаль хезмәт идарәсе алынган документларны конкурс комиссиясенә тапшыра.

14. Конкурска «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясында каралган чикләүләр булган затлар кертелми.

15. Конкурс кандидатларның һөнәри дәрәҗәсен бәяләүдән, аларның Башкарма комитет Җитәкчесе вазыйфасына квалификация таләпләренә туры килүеннән, мәгариф, граждан яисә башка дәүләт һәм (яисә) муниципаль хезмәт узу, башка хезмәт эшчәнлеген башкару турында тапшырылган документлар нигезендә, шулай ук конкурс комиссиясе әгъзалары белән шәхси әңгәмәдән гыйбарәт.

Кандидатлар конкурс комиссиясе утырышына шәхси әңгәмә өчен, гариза бирү датасы һәм вакыты буенча, чират тәртибендә чакырыла.

16. Конкурс комиссиясе утырышы, конкурс комиссиясе әгъзаларының билгеләнгән саныннан кимендә өчтән икесе катнашса, хокуклы дип санала.

17. Фикер алышу, конкурс нигезендә сайлап алу һәм йомгаклар ясау кандидатлар катнашыннан башка гамәлгә ашырыла.

18. Конкурс комиссиясе карары ачык тавыш бирү юлы белән, комиссия әгъзаларының күпчелек тавышы нигезендә кабул ителә. «Хуплыйм» һәм «Каршы» тавышлар тигез булган очракта, рәис тавышы хәлиткеч булып тора. Карарны утырышта катнашкан конкурс комиссиясе әгъзалары имзалый.

19. Конкурс нәтиҗәләре турындагы карар кандидатларга хәбәр ителә.

20. Конкурс нәтиҗәләре һәм кандидатлар турындагы мәгълүмат конкурс комиссиясе тарафыннан Шәһәр Советына тапшырыла.

21. Конкурс комиссиясе Шәһәр Советына Башкарма комитет Җитәкчесе вазыйфасына дәгъва кылучылар арасыннан кимендә ике кандидатураны тәкъдим итә.

22. Шәһәр Советы депутатларының билгеләнгән саныннан күпчелеге аның кандидатурасы өчен тавыш бирсә, зат Башкарма комитет Җитәкчесе вазыйфасына билгеләнә.

23. Конкурс үткәрү нәтиҗәсендә Башкарма комитет Җитәкчесе вазыйфасына квалификация таләпләренә туры килүче кандидатлар ачыкланмаса, конкурс комиссиясе тәкъдиме буенча, Шәһәр Советы кабат конкурс уздыру турында карар кабул итә.

Конкурс комиссиясе тәкъдим иткән кандидатларның берсе дә Башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасына билгеләнмәгән очракта, Шәһәр Советы тарафыннан кабат конкурс уздыру турында карар кабул ителә.

24. Конкурс нәтиҗәләре буенча Башкарма комитет Җитәкчесен билгеләү турындагы карар Шәһәр Советы тарафыннан чираттагы утырышта кабул ителә.

25. Башкарма комитет Җитәкчесенә конкурста катнашуга кертелмәгән конкурсантларның һәм конкурста катнашкан кандидатларның документлары Шәһәр Советы тарафыннан Башкарма комитет Җитәкчесен билгеләү турында карар кабул ителгән көннән соң 30 көн эчендә язма гариза буенча кайтарылырга мөмкин. Бу вакыт узганчы документлар Шәһәр Советы аппаратында саклана, шуннан соң юк ителергә тиеш.

26. Конкурста катнашуга бәйле чыгымнар (конкурс үткәрү урынына бару һәм кире кайту, торак урынны наемга алу, яшәү, элемтә чаралары хезмәтләреннән файдалану һәм башкалар) кандидатларның үз хисабыннан башкарыла.

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибенә 1 нче кушымта
(Форма)

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру комиссиясенә

Гариза

Мин, ________________________________________________ (Ф.И.А.и.) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурста катнашырга телим.

Россия Федерациясе гражданы булуымны, хокуктан файдаланугa сәләтле булуымны, муниципаль хезмәткә керү һәм аны узу өчен муниципаль хезмәт турындагы законнарда билгеләнгән чикләүләрнең минем тарафтан үтәлүен, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Җитәкчесе вазыйфасына куела торган квалификация таләпләренә туры килүемне, әлеге конкурста катнашу өчен тапшырыла торган документлардагы белешмәләр чынбарлыкка туры килүен, документларымның ялган булмавын раслыйм.

Кушымта:
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________

(Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибенең 8 пунктында күрсәтелгән һәм теркәлеп бирелә торган документлар исемлеге)

________________ (имза)

________________ (дата)

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибенә 2 нче кушымта

(Форма)

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурста катнашучының шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалыгы

Мин,

______________________________________________________________________

*(Ф.И.А.и. тулысынча)*

Теркәлү адресы:_______________________________________

______________________________________________________________________

(шәхесне раслаучы документ: __________серия_________________номер,

бирелгән_____________________________________________________________

______________________________________________________________________)

*(кайчан һәм кем тарафыннан бирелгән)*

«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы нигезендә, 423805, Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Хәсән Туфан проспекты. 23 нче йорт адресы буенча урнашкан конкурс комиссиясенә, Шәһәр Советына, Башкарма комитетның персонал белән эшләү һәм муниципаль хезмәт идарәсенә минем Башкарма комитет Җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурста катнашу өчен биргән шәхси мәгълүматларымны, шул исәптән, фамилия, исем, атамның исеме, элекке фамилия, исем, атамның исеме, туган урын һәм ел, җенес, гражданлык, чит телләр һәм Россия Федерациясе халыклары телләрен белү; белем; гыйльми дәрәҗә; өстәмә һөнәри белем; һөнәр (белгечлек); хезмәт стажы (шул исәптән дәүләт граждан һәм муниципаль хезмәт стажы); классны чин (хәрби яки махсус исем); дәүләт бүләкләре һәм башка бүләкләр, аерымлык билгеләре (кем һәм кайчан бүләкләгән) булу; эшкә кабул итү, күчерү, билгеләнү һәм эштән азат итү турында мәгълүматлар; гаилә хәле (шул исәптән: гаилә составы, туганлык дәрәҗәсе, фамилия, исем, атасының исеме, якын туганнарның туган көне, аларның эш һәм уку урыны); паспорттагы мәгълүматлар; гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында таныклык; яшәү һәм теркәлү урыны; элемтә өчен телефон номеры; шәхси (персонификацияләнгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслаучы документ номеры; хәрби исәпкә алу турында мәгълүмат; салым түләүченең идентификацион номеры; хөкем ителгәнлек булу (булмау); эш чорында рәсмиләштерелгән дәүләт серенә рөхсәт, керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре

торган авыру булу (булмау) турында медицина учреждениесе бәяләмәсе, шулай ук «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт кадрлар составының бердәм мәгълүмат системасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы кысаларында минем эшчәнлек мәсьәләләренә караган һәм кадрлар эшен башкару өчен кирәкле башка шәхси мәгълүматларны, шул исәптән: автоматлаштыру чараларын кулланып яисә мондый чараларны кулланмыйча, туплау, язу системалаштыру, җыю, саклауга, төгәлләштерүгә (яңарту, үзгәртүгә), алу, куллану, башкаларга тапшыруга (тарату, бирүгә) шәхессезләндерүгә (блокировкалау, юкка чыгаруга) рөхсәт бирәм.

Югарыда күрсәтелгән шәхси белешмәләрне шулай ук муниципаль хезмәт турындагы законнарны гамәлгә ашыруны тәэмин итү, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларын үтәү максатларында тапшырам

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының персонал белән эшләү һәм муниципаль хезмәт идарәсенең минем шәхси мәгълүматларны, Башкарма комитет Җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурста катнашу өчен документларны тикшерү максатларында, Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе вәкаләтле дәүләт органнарына тапшыру хокукына ия булуына риза. Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясенең югарыда күрсәтелгән дәүләт органнары исемнәре һәм адресы алар турында Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе норматив хокукый актлары белән расланган нигезләмәләр белән билгеләнде.

Мин:

1) шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык әлеге килешүгә имза кую датасыннан алып, Башкарма комитет Җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс узу срогы дәвамында гамәлдә булуы турында,

2) шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыкның минем ирекле формада язма гаризам нигезендә кире алынырга мөмкинлеге турында,

3) шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыкны кире алган очракта, югарыда күрсәтелгән органнарның, «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясындагы 1 өлешенең 2 - 11 пунктларында, 10 статьясындагы 2 өлешендә һәм 11 статьясындагы 2 өлешендә күрсәтелгән нигезләр булганда, шәхси мәгълүматларны эшкәртүне дәвам итәргә хокуклы булуы турында хәбәрдар.

Югарыда күрсәтелгән органнар тарафыннан шәхси мәгълүматларымны эшкәртү «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләренә туры китереп башкарыла.

________________ ________________________________

__________________

Дата Ф.И.А.и. имза

Шәһәр Советының
1/11 Карарына
2 нче кушымта
22 сентябрь, 2025 ел

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Җитәкчесе вазыйфасына билгеләнүче зат белән
контракт проекты

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасының муниципаль хезмәт турында кодексы» 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы (алга таба – Устав) нигезендә эш итүче Яр Чаллы шәһәре Хакиме (алга таба – шәһәр Хакиме) бер яктан һәм Шәһәр Советының 2025 елның ________________номерлы Карары белән билгеләнгән ____________ Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты Җитәкчесе (алга таба – Башкарма комитет Җитәкчесе) икенче яктан түбәндәгеләр хакында әлеге контрактны төзеделәр.

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге контракт Башкарма комитет Җитәкчесе һәм җирле үзидарә органнары арасында хезмәт һәм башка мөнәсәбәтләрне җайга сала, законнар һәм Устав нигезендә әлеге контракт якларының хокукларын һәм бурычларын билгели.

1.2. Башкарма комитет Җитәкчесе законнар, Устав һәм әлеге контрактта билгеләнгән шартларда әлеге контрактның гамәлдә булу чорына Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты (алга таба - Башкарма комитет) белән җитәкчелек итү йөкләмәсен ала.

## 2. Контрактның төп шартлары

2.1. Башкарма комитет Җитәкчесе вазыйфаларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Шәһәр Советы (алга таба – Шәһәр Советы) тарафыннан конкурс нәтиҗәләренән чыгып билгеләнә.

2.2.Башкарма комитет Җитәкчесе муниципаль хезмәткәр була һәм Башкарма комитетны җитәкли.

2.3. Башкарма комитет Җитәкчесе үз эшчәнлегендә Шәһәр Советы һәм шәһәр Хакиме контролендә тора һәм алар каршында хисап тота.

2.4. Әлеге контракт буенча башкарыла торган хезмәт Башкарма комитет Җитәкчесе өчен төп хезмәт була.

## 3. Башкарма комитет Җитәкчесенең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өлешендә хокуклары һәм бурычлары

3.1. Башкарма комитет Җитәкчесенең хокуклары һәм бурычлары законнар, Устав, башка муниципаль хокукый актлар һәм әлеге контракт белән билгеләнә.

3.2. Башкарма комитет Җитәкчесе:

3.2.1. Муниципаль берәмлекнең Башкарма комитеты эшчәнлегенә бер җитәкче идарәсе принцибында җитәкчелек итә һәм Башкарма комитет компетенциясендәге вәкаләтләрнең үтәлеше өчен Шәһәр Советы һәм шәһәр Хакиме каршында шәхсән җавап бирә;

3.2.2. Шәһәр Советы, шәһәр Хакиме, җирле үзидарәнең башка органнары, шул исәптән башка муниципаль берәмлекләр, дәүләт хакимияте органнары, гражданнар һәм оешмалар белән мөнәсәбәтләрдә Башкарма комитет исеменнән эш йөртә;

3.2.3. Шәһәр Советы каравына муниципаль берәмлекнең комплекслы социаль-икътисадый үсеше планнары һәм программалары проектларын һәм аларның үтәлеше турындагы хисапларны тапшыра;

3.2.4.Башкарма комитет структурасы проектын, Башкарма комитет хезмәткәрләренең чикләнгән санын һәм аларның хезмәтенә түләү фондын муниципаль берәмлекнең Шәһәр Советы раславына куя, расланган структура, хезмәткәрләрнең билгеләнгән чик санын һәм аларның хезмәтенә түләү фонды нигезендә Башкарма комитетның штат расписаниесен раслый;

3.2.5.Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасарларын, Башкарма комитетның тармак (функциональ) һәм территориаль органнары җитәкчеләрен эшкә билгели һәм азат итә, үз урынбасарларына вазыйфалар йөкли, Башкарма комитетның муниципаль хезмәткәрләрен һәм башка хезмәткәрләрне вазыйфага билгели һәм азат итә, аларның эшчәнлеген контрольдә тота, аларга карата кызыксындыру һәм дисциплинар җаваплылык чараларын куллана;

3.2.6. расланган бюджет нигезендә муниципаль берәмлекнең акча средстволарыннан файдалана, законнар нигезендә бюджет счетларын һәм муниципаль берәмлекнең башка счетларын ача һәм яба;

3.2.7. Шәһәр Советына үз эшчәнлеге һәм Башкарма комитет эшчәнлеге хакында еллык хисаплар, шул исәптән Шәһәр Советы куйган мәсьәләләрне хәл итү турында хисап бирә;

3.2.8. Башкарма комитет эшчәнлеге турында халыкка даими рәвештә хәбәр итә, Башкарма комитет хезмәткәрләре тарафыннан гражданнарны кабул итүне оештыра, айга кимендә бер тапкыр гражданнарны шәхси кабул итүне гамәлгә ашыра, гражданнарның тәкъдимнәрен, гаризаларын һәм шикаятьләрен карый, алар буенча карарлар кабул итә;

3.2.9. дәүләт һәм башка органнарда муниципаль берәмлекнең мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын күрә, Башкарма комитет исеменнән судка гариза бирә, ышаныч язулары тапшыра;

3.2.10. законнар, Устав, Шәһәр Советы Карарлары һәм әлеге контракт нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

3.3. Башкарма комитет Җитәкчесе муниципаль берәмлек исеменнән мөлкәти һәм башка хокуклар һәм бурычлар алырга һәм гамәлгә ашырырга, ышаныч язуыннан башка судта чыгыш ясарга хокуклы.

3.4.Башкарма комитет Җитәкчесе федераль законнар, Татарстан Республикасы законнарында, Уставта, Шәһәр Советының норматив хокукый актларында билгеләнгән вәкаләтләре чикләрендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча Башкарма комитет карарларын һәм җирле үзидарә органнарына федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле мәсьәләләр буенча карарлар кабул итә, шулай ук Башкарма комитетның эшен оештыру мәсьәләләре буенча боерыклар чыгара.

3.5. Башкарма комитет Җитәкчесе бурычлы:

3.5.1. Россия Федерациясе Конституциясен, Татарстан Республикасы Конституциясен, федераль законнарны һәм Татарстан Республикасы законнарын, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларын, Устав һәм башка муниципаль хокукый актларны үтәргә, Шәһәр Советы һәм шәһәр Хакиме карарларын үтәргә һәм аларның үтәлешен тәэмин итәргә;

3.5.2. гражданнарның һәм оешмаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәүне һәм яклауны тәэмин итәргә;

3.5.3. шәһәр Хакиме, Шәһәр Советы, җирле үзидарәнең башка органнары белән законнарда, Уставта, башка муниципаль хокукый актларда һәм әлеге контрактта билгеләнгән тәртиптә һәм рәвешләрдә үзара хезмәттәшлекне гамәлгә ашырырга;

3.5.4. вазыйфаи бурычларын намус белән башкарырга;

3.5.5. хезмәт бурычларын үтәү өчен кирәкле квалификация дәрәҗәсен сакларга;

3.5.6. дәүләт серен һәм федераль законнар белән саклаучы башка серне тәшкил иткән мәгълүматларны, шулай ук вәкаләтләрен башкаруга бәйле рәвештә үзенә билгеле булган мәгълүматларны, шул исәптән гражданнарның шәхси тормышына һәм сәламәтлегенә, намусына һәм абруена кагылышлы мәгълүматларны игълан итмәскә;

3.5.7. законнар нигезендә муниципаль хезмәткә бәйле чикләүләрне һәм тыюларны үтәргә;

3.5.8. Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә шәхси һәм гаилә әгъзалары турында белешмәләрне тапшырырга;

3.5.9. дәүләт һәм муниципаль милекне, шул исәптән аңа вәкаләтләрне башкару өчен бирелгән милекне сакларга;

3.5.10. шәһәр Хакименә язма рәвештә Россия Федерациясе гражданлыгын яисә чит ил гражданына җирле үзидарә органнарына сайлану хокукын бирә

торган Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә катнашучы чит ил гражданлыгын туктату турында, яисә чит ил гражданлыгын (подданный булу) алу яисә яшәүгә рөхсәт алу, яки Россия Федерациясе гражданының чит ил территориясендә даими яшәү хокукын раслаучы яки Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсе нигезендә җирле үзидарә органнарына сайлану хокукына ия булган чит ил гражданының даими яшәү хокукын раслаучы башка документның гамәлдән чыгуы турында бу хакта билгеле булган көндә, Россия Федерациясе гражданлыгы яисә чит ил гражданлыгы туктатылу яки чит ил гражданлыгын (подданство), яшәүгә рөхсәт яки әлеге пунктта каралган башка документ алу көненән башлап, биш көннән дә соңга калмый хәбәр итәргә.

3.6. Вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда Башкарма комитет Җитәкчесе мәнфәгатьләр конфликты килеп чыгу очракларын булдырмаска тиеш.

Мәнфәгатьләр конфликты дигәндә, Башкарма комитет Җитәкчесенең шәхси кызыксынуы аның вазыйфаи бурычларын объектив үтәвенә йогынты ясый яисә йогынты ясый ала торган, һәм шул вакытта Башкарма комитет җитәкчесенең шәхси кызыксынуы белән гражданнарның, оешмаларның, җәмгыятьнең, Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, муниципаль берәмлекнең законлы мәнфәгатьләре арасында гражданнарның, оешмаларның, җәмгыятьнең, Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, муниципаль берәмлекнең законлы мәнфәгатьләренә зыян китерергә сәләтле каршылык барлыкка килә яисә килеп чыгарга мөмкин булган вәзгыять аңлашыла.

Башкарма комитет Җитәкчесенең шәхси кызыксынуы дигәндә Башкарма комитет Җитәкчесенең вазыйфаи бурычларын үтәгәндә Башкарма комитет Җитәкчесенә, аның гаилә әгъзаларына, туган булучы яки туганлыкта торучы башка затларга (ата-аналар, ир белән хатын, балалар, ир туганнары, кыз туганнары, шулай ук иренең (хатынының) кыз туганнары, ир туганнары, ата-анасы, баласы һәм балаларының ире (хатыны) шулай ук Башкарма комитет Җитәкчесе финанс яисә башка йөкләмәләр белән бәйле гражданнар яки оешмалар өчен акчалата яки натураль рәвештә керемнәр (нигезсез баю), турыдан-туры матди файда рәвешендә керемнәр алу мөмкинлеге аңлашыла.

Башкарма комитет Җитәкчесендә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксыну барлыкка килгән очракта, Башкарма комитет Җитәкчесе бу хакта язма рәвештә Шәһәр Хакименә хәбәр итәргә һәм мондый конфликтны булдырмау чараларын күрергә тиеш.

3.7. Башкарма комитет Җитәкчесе законнарда, Уставта, башка муниципаль хокукый актларда, әлеге контрактта билгеләнгән башка бурычларны үтәргә тиеш.

3.8. Башкарма комитет Җитәкчесе үз вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрендә эш итәргә, хокукларын һәм йөкләмәләрен намуслы һәм акыллы итеп башкарырга тиеш.

3.9. Башкарма комитет Җитәкчесе Яр Чаллы шәһәре җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген күрсәтүче «Шәһәр округлары һәм муниципаль районнар органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү турындагы» 2008 елның 28 апрелендәге 607 номерлы Россия Федерациясе

Президенты Указы һәм «Шәһәр округлары һәм муниципаль районнар органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү турында» 2012 елның 17 декабрендәге 607 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указын һәм «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 601 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указының 2 пункты «и» пунктчасын гамәлгә ашыру буенча чаралар турында» 2012 елның 7 маендагы 1317 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү өчен кулланыла торган күрсәткечләр дәрәҗәсенә ирешергә тиеш.

## 4. Җирле үзидарә органнарына федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары белән тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өлешендә Башкарма комитет Җитәкчесенең хокуклары һәм бурычлары

4.1. Җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен башкарганда Башкарма комитет Җитәкчесе түбәндәгеләргә хокуклы:

4.1.1. җирле узидарә органнарына аерым дәүләт вәкаләтләрен тапшыра торган федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән, шулай ук федераль башкарма хакимият органнары һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары тарафыннан кабул ителгән норматив хокукый актлар белән билгеләнгән нигезләмәләр нигезендә һәм аларны үтәү йөзеннән, федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән очракларда, шушы вәкаләтләрне башкаруга бәйле мәсьәләләр буенча карарлар, шулай ук аерым дәүләт вәкаләтләрен башкару өчен үтәлеше кирәк булган Башкарма комитет эшен оештыру мәсьәләләре буенча күрсәтмәләр чыгарырга;

4.1.2. федераль башкарма хакимият органнарыннан, аларның территориаль органнарыннан җирле үзидарә органнарына федераль законнар белән тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматны соратып алырга;

4.1.3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетыннан, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарыннан һәм аларның территориаль органнарыннан Татарстан Республикасы законнары белән җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматны соратып алырга;

4.1.4. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибе турында, шулай ук аларны тиешле матди ресурслар һәм финанс чаралары белән үтәүне тәэмин итү турында тәкъдим белән мөрәҗәгать итәргә;

4.1.5. Шәһәр Советына Уставта каралган очракларда һәм тәртиптә үзләренә тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен үз матди ресурслар һәм финанс чараларыннан өстәмә файдалану турында тәкъдимнәр кертергә;

4.1.6. аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча законнардагы таләпләрне бозуны бетерү турында вәкаләтле дәүләт органнары күрсәтмәләренә суд тәртибендә шикаять белдерергә;

4.1.7. аерым дәүләт вәкаләтләрен бирүне күздә тоткан федераль законнар яисә Татарстан Республикасы законнары нигезендә башка хокуклардан файдаланырга.

4.2. җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен башкарганда Башкарма комитет Җитәкчесе түбәндәгеләрне үтәргә тиеш:

4.2.1. Башкарма комитетның аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле эшен оештырырга;

4.2.2. аерым дәүләт вәкаләтләрен башкару өчен бирелгән матди ресурсларның һәм финанс чараларының, шулай ук шушы вәкаләтләрне башкару өчен Уставта каралган очракларда һәм тәртиптә жирле узидарә органнары тарафыннан өстәмә рәвештә файдаланыла торган матди ресурсларының һәм финанс чараларының сакланышын һәм алардан максатчан файдалануны тәэмин итүгә юнәлдерелгән чараларны үз вәкаләтләре чикләрендә күрергә;

4.2.3. жирле үзидарә органнарына аерым дәүләт вәкаләтләрен тапшыра торган федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән нигезләмәләр нигезендә һәм шуларны үтәү йөзеннән нәшер ителгән муниципаль хокукый актлар турында белешмәләрне Россия Федерациясенең вәкаләтле дәүләт органнарына һәм (яисә) Татарстан Республикасының вәкаләтле дәүләт органнарына тапшырырга;

4.2.4. җирле үзидарә органнарына аерым дәүләт вәкаләтләрен тапшыра торган федераль законнар белән билгеләнгән тәртиптә шушы вәкаләтләрне башкару турында хисапларны Россия Федерациясенең вәкаләтле дәүләт органнарына тапшырырга;

4.2.5. жирле үзидарә органнарына аерым дәүләт вәкаләтләрен тапшыра торган Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән тәртиптә шушы вәкаләтләрне башкару турында хисапларны Татарстан Республикасының вәкаләтле дәүләт органнарына тапшырырга;

4.2.6. федераль законнар белән җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен башкаруны тикшереп торуда Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнарына ярдәм күрсәтергә;

4.2.7. Татарстан Республикасы законнары белән җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен башкаруны тикшереп торуда Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына ярдәм күрсәтергә;

4.2.8. үз вәкаләтләре чикләрендә Россия Федерациясенең вәкаләтле дәүләт органнарының язма күрсәтмәләрендә жирле үзидарә органнары яисә җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары тарафыннан федераль законнар белән жирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен башкару мәсьәләләре буенча федераль законнар таләпләрен бозуларны бетерүгә юнәлдерелгән чаралар күрергә;

4.2.9. үз вәкаләтләре чикләрендә Татарстан Республикасы дәүләт органнарының язма күрсәтмәләрендә күрсәтелгән Татарстан Республикасы закон органнарының җирле үзидарә органнары яисә җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары тарафыннан Татарстан Республикасы законнарында җирле

үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча таләпләрен бозуларны бетерүгә юнәлдерелгән чаралар күрергә;

4.2.10. вәкаләтле дәүләт органнарына аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга таләп ителә торган финанс чыгымнары исәп-хисапларын тапшырырга;

4.2.11. аерым дәүләт вәкаләтләрен жирле үзидарә органнары тарафыннан башкаруны туктату турында федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белен билгеләнгән вакытларда матди ресурсларны һәм файдаланылмаган финанс чараларын кире кайтарырга;

4.2.12. аерым дәүләт вәкаләтләрен жирле үзидарә органнарына тапшыра торган федераль законнар яисә Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән шартлар килеп туганда һәм тәртиптә жирле үзидарә органнары тарафыннан шушы вәкаләтләрне башкаруны туктатуга юнәлдерелгән чаралар күрергә.

Шәһәр Хакименең хокуклары һәм бурычлары

5.1. Шәһәр Хакиме хокуклы:

5.1.1.Башкарма комитет Җитәкчесе үз вазыйфаларын башкарганда, аннан Россия Федерациясе Конституциясен, Татарстан Республикасы Конституциясен, федераль законнарны, Татарстан Республикасы законнарын, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актларын, Уставны, Шәһәр Советы Карарларын һәм шәһәр Хакименең муниципаль хокукый актларын үтәүне таләп итәргә;

5.1.2. үз вәкаләтләре кысасында Башкарма комитет Җитәкчесе өчен үтәү мәҗбүри булган йөкләмәләр бирергә, Башкарма комитет Җитәкчесеннән шәһәр Хакиме, Шәһәр Советы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен кирәкле, шул исәптән Башкарма комитет эшчәнлеген тикшереп торуга бәйле сорала торган яисә башка килешенгән вакытларда тапшырылырга тиешле бәяләмәне, документларны, белешмәне һәм башка мәгълүматны соратып алырга;

5.1.3.Башкарма комитет Җитәкчесенә карата законнар һәм муниципаль хокукый актлар нигезендә бүләкләү чараларын кулланырга;

5.1.4. Башкарма комитет Җитәкчесен хезмәт бурычларын үтәмәгән һәм (яисә) тиешенчә үтәмәгән өчен законнар нигезендә дисциплинар җаваплылыкка тартырга;

5.1.5.Башкарма комитет Җитәкчесе тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә кагылышлы өлештә әлеге контракт шартларын бозуга бәйле рәвештә әлеге контрактны вакытыннан алда өзү турында судка мөрәҗәгать итәргә;

5.1.6. Шәһәр Хакиме Башкарма комитет Җитәкчесенең законнарда, муниципаль хокукый актларда һәм әлеге контрактта каралган хокукларын һәм гарантияләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү чараларын күрә.

5.2. Федераль законнар һәм башка норматив хокукый актлар белән вәкаләт бирелгән органнар һәм урындагы затлар таләпләре буенча һәм законнарда

каралган башка очракларда вазыйфаи бурычларын үтәү өчен медицина бәяләмәсе нигезендә каршы күрсәткечләр булуы ачыкланган очракта Шәһәр Хакиме Башкарма комитет Җитәкчесен били торган вазыйфасыннан читләштерергә (вазыйфаи бурычларын үтәргә рөхсәт бирмәскә) тиеш.

5.3. Башкарма комитет Җитәкчесе һәм Башкарма комитет органнары белән үзара хезмәттәшлек буенча шәһәр Хакименең башка вәкаләтләре законнар, Устав һәм башка муниципаль хокукый актлар белән билгеленә.

## 6. Башкарма комитет Җитәкчесе хезмәтенә түләү һәм эш вакыты

6.1. Башкарма комитет Җитәкчесенә гамәлдәге законнар һәм Шәһәр Советының норматив хокукый актлары нигезендә хезмәт хакы түләнә.

6.2. Башкарма комитет Җитәкчесенең вазыйфаи оклады күләме 50169 (илле мең бер йөз алтмыш тугыз) сум тәшкил итә һәм Шәһәр Советы карары нигезендә индексацияләнә.

6.3. Башкарма комитет Җитәкчесе үз эшчәнлеген нормаланмаган хезмәт көне шартларында гамәлгә ашыра.

## 7. Башкарма комитет Җитәкчесе вәкаләтләрен тормышка ашыруның социаль-көнкүреш шартлары һәм башка шартлар

7.1.Башкарма комитет Җитәкчесенә хезмәт вазыйфаларын үтәү өчен җирле бюджет средстволары хисабына эш графигы тәүлек буена исәпләнгән машина йөртүче белән хезмәт автомашинасы һәм мобиль элемтә чаралары бирелә.

7.2.Башкарма комитет Җитәкчесенә командировка чыгымнары кире кайтарыла, гамәлдәге законнарда каралган башка түләүләр түләнә, шулай ук ел саен түләүле ял һәм законнар, Шәһәр Советының муниципаль хезмәткәрләр өчен норматив хокукый актлары белән Шәһәр Хакиме тарафыннан билгеләнгән башка гарантияләр бирелә.

## 8. Башкарма комитет Җитәкчесенең вәкаләтләре чоры

8.1. Башкарма комитет Җитәкчесе әлеге контракт төзелгән көннән үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга керешә.

Әлеге контракт Башкарма комитет Җитәкчесе белән затны Башкарма комитет Җитәкчесе вазыйфасына билгеләү турында карар кабул иткән Шәһәр Советының вәкаләтләре чорына (яңа чакырылыш Шәһәр Советы эшли башлаганга кадәр) төзелә һәм биш елны тәшкил итә

8.2. Башкарма комитет Җитәкчесенең вәкаләтләре түбәндәге очракларда вакытыннан алда туктатыла:

8.2.1. үлгәндә;

8.2.2. үз теләге белән эштән киткәндә;

8.2.3. әлеге контракт законда билгеләнгән тәртиптә өзелгәндә;

8.2.4. 33-ФЗ номерлы Федераль законының 23 статьясы нигезендә вазыйфаларны үтәүдән читләштерелгәндә;

8.2.5. суд тарафыннан эшкә сәләтсез һәм эшкә сәләте чикле, дип танылганда;

8.2.6. суд тарафыннан хәбәрсез югалган һәм вафат булган, дип игълан ителгәндә;

8.2.7. аңа карата судның гаепләү карары закон көченә кергәндә;

8.2.8. Россия Федерациясе чикләреннән тыш даими яшәү урынына күченгәндә;

8.2.9. Россия Федерациясе гражданлыгының туктатылуы яисә чит дәүләт гражданлыгын (подданство) яки яшәүгә рөхсәтен яисә Россия Федерациясе гражданының чит дәүләт территориясендә даими яшәү хокукын раслый торган башка документы булуы;

8.2.10. хәрби хезмәткә яисә аны алмаштыручы альтернатив гражданлык хезмәтенә чакырылганда;

8.2.11. 33-ФЗ номерлы Федераль законының 12 статьясындагы 6 һәм 7 өлешләре нигезендә муниципаль берәмлек үзгәртеп корылганда;

8.2.12. муниципаль берәмлектә сайлаучылар саны 25 процентка артканда;

8.2.13. Башкарма комитет җитәкчесе вәкаләтләрен башкаручының Башлык вазыйфасына керешүе;

8.2.14. җирле администрация башлыгы вәкаләтләрен башкаручы муниципаль берәмлек башлыгы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктатылуы;

8.2.15. халыкның турыдан-туры ихтыяр белдерүе белән кабул ителгән карарны гамәлгә ашыру өчен кирәкле муниципаль хокукый актны чыгару срогын бозу;

8.2.16. чит ил агенты статусына ия булу.

8.3. Шәһәр Советы вәкаләтләре чоры узгач яки аның вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылганда, Башкарма комитет Җитәкчесе үз вәкаләтләрен билгеләнгән тәртиптә яңа Башкарма комитет Җитәкчесе билгеләнеп куелганчы һәм аның белән контракт төзелгәнче дәвам итә.

## 9. Якларның җаваплылыгы

9.1. Әлеге контрактны үтәмәгән һәм (яисә) тиешенчә үтәмәгән өчен яклар гамәлдәге законнар нигезендә җаваплылыкка тартыла.

9.2. Башкарма комитет Җитәкчесе үз гаебе белән муниципаль берәмлеккә китерелгән зыян өчен тулысынча матди жаваплы була. Әлеге җаваплылык тиешле суд карары нигезендә йөкләнә.

9.3. Башкарма комитет Җитәкчесе федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән җирле үзидарә органнарына бирелгән аерым дәүләт вәкаләтләрен башкармаган яисә тиешенчә гамәлгә ашырмаган өчен муниципаль берәмлеккә шушы максатларга бүлеп бирелгән матди ресурслар һәм финанс чаралары чикләрендә федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән җаваплы була.

9.4. Шәһәр Хакиме мәнфәгатьләр конфликтын жайга салу чорында Башкарма комитет Җитәкчесе биләгән вазыйфасыннан читләштерергә (вазыйфаи бурычларын үтәүне тыярга) хокуклы. Мондый очракта, Башкарма

комитет Җитәкчесенең биләгән вазыйфасыннан читләштерелгән вакытка акчалата айлык хезмәт хакы сакланып кала.

10. Контрактны үзгәртү һәм өзү.
Бәхәсләрне хәл итү

10.1. Һәр як контрактны үзгәртү (төгәлләштерү) яисә өстәү турындагы мәсьәләне икенче як алдына куярга хокуклы, ул Шәһәр Советы карары белән расланганнан соң, контрактка теркәлүче өстәмә килешү белән рәсмиләштерелә.

10.2. Башкарма комитет Җитәкчесе белән контракт яклар килешүе буенча түбәндәгеләр тарафыннан бирелгән гариза нигезендә суд тәртибендә вакытыннан алда өзелергә мөмкин:

10.2.1. Шәһәр Советы яисә шәһәр Хакиме тарафыннан – җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә кагылышлы өлешендә контракт шартларын бозуга бәйле рәвештә, шулай ук Федераль законда каралган башка очракларда:

10.2.2. Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан – федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга кагылышлы өлешендә контракт шартларын бозуга бәйле рәвештә, шулай ук Федераль законда каралган башка очракларда;

10.2.3. Башкарма комитет Җитәкчесе тарафыннан – җирле үзидарә органнары һәм (яки) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан контракт шартларын бозуга бәйле рәвештә.

10.3. Яклар ризалыгын күздә тоткан очракларда, контрактны вакытыннан алда өзү турындагы тәкъдим, контрактны туктатуның фаразланган вакытына кадәр ике айдан да соңга калмыйча, башка якка язма рәвештә җибәрелергә тиеш.

10.4. Яклар арасындагы бәхәсләр гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә хәл ителә.

11. Контрактның гамәлдә булу вакыты

11.1. Әлеге контракт Башкарма комитет Җитәкчесенең вәкаләтләр чоры узганга кадәр, әлеге Контрактның 8.1 пункты белән билгеләнгән тәртиптә, Башкарма комитетының яңа Җитәкчесе билгеләнгәнгә һәм аның белән контракт төзегәнгә кадәр гамәлдә була. Башкарма комитетның яңа Җитәкчесе белән контракт төзелгән көннән әлеге контракт гамәлдән чыгарыла һәм Башкарма комитет белән җитәкчелек итү вәкаләтләре Башкарма комитетның яңа Җитәкчесенә тапшырыла.

11.2. Башкарма комитет Җитәкчесе белән төзелгән контракт аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга кагылышлы өлешендә, әгәр дә аерым дәүләт вәкаләтләренең гамәлдә булу чоры билгеләнгән булса һәм ул вәкаләтләренең гамәлдә булу чорыннан узып китмәсә, аның вәкаләтләре чоры дәвамында гамәлдә була.

11.3. Законнар һәм әлеге контрактның 8.2. пункты нигезендә Башкарма комитет Җитәкчесенең вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылган көннән (әлеге контрактның 11.1 нче пунктында билгеләнгән вакыттан алдарак) әлеге контракт вакытыннан алда гамәлдән чыгарыла.

## 12. Йомгаклау нигезләмәләре

12.1. Әлеге контракт яклар имза куйган көннән үз көченә керә.

12.2. Вәкаләтләр срогы беткәч яисә вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылгач, Башкарма комитет Җитәкчесе үз эшендә булган барлык басмаларны, штампларны, финанс һәм башка документларны яңа билгеләнгән Башкарма комитет Җитәкчесенә яисә аның вазыйфаларын вакытлыча башкаручы затка кабул итү-тапшыру акты буенча тапшырырга тиеш.

12.3. Әлеге контракт бер үк төрле юридик көчкә ия өч нөсхәдә төзелгән, аның бер нөсхәсе – Башкарма комитетның кадрлар хезмәтендә (Башкарма комитет Җитәкчесенең шәхси эшендә), бер нөсхәсе – шәһәр Хакимендә, бер нөсхәсе – Башкарма комитет җитәкчесендә саклана.

Якларның реквизитлары һәм имзалары:

| | |
|---|---|
| Шәһәр Хакиме | Яр Чаллы шәһәре<br>муниципаль берәмлеге<br>Башкарма комитеты Җитәкчесе<br>Паспорт белешмәләре:<br><br>Адресы: |
| ______________________<br>(имза) Ф.И.А.и. | ______________________<br>(имза) Ф.И.А.и. |